БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» 07 2025 ел № 198

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәү урыны буенча бала тууны теркәгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гражданнарына бала (балалар) тугач бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында демографик вәзгыятьне яхшырту һәм халык саны кимүнең тискәре тенденцияләрен бетерү максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2025 елның 15 маендагы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнарга бала (балалар) тугач бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 154 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәү урыны буенча бала тууны теркәгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. 2025 елда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гражданнарына агымдагы елда бала тугач 25000,00 (егерме биш мең) сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү түбәндәге шартларны үтәгәндә башкарыла:

2.1. Бала (балалар), баланың (балаларның) ата-аналары Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшәү урыны буенча теркәлгән булырга тиеш;

2.2. Баланың (балаларның) ата-анасы бала туу вакытына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә бер елдан артык эшләгән булырга тиеш, махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш.

2.3. Баланың (балаларның) ата-анасының икесенең дә Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, штраф пенялары, процентлар буенча, шулай ук үзара салым җыемнары буенча түләнмәгән әҗәтләре юк.».

1.2. 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү өчен законлы вәкил (мөрәҗәгать итүче) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район башкарма комитетының ГХАТ бүлегенә (алга таба - вәкаләтле орган) түбәндәге документларны тапшыра:

- балаларның туу турында таныклыклары;

- бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү турында гариза (алга таба - гариза);

- әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

- ата-аналарның паспорт күчермәсе теркәү битләре белән;

- акчаларны күчерү өчен банк реквизитлары;

- ата-аналарның хезмәт кенәгәсеннән (электрон хезмәт кенәгәсеннән) өземтә;

- махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен - хәрби комиссариаттан оборона министрлыгы белән контракт төзү турында белешмә;

- ата-ананың икесенең дә Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, штраф пенялары, процентлар буенча түләнмәгән әҗәтләре булмавы турында белешмә;

- үзара салым җыемнары буенча түләнмәгән әҗәтләре булмау турында белешмә.

1.3. 6.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар:

- 14 яшькә кадәрге балаларны теркәүне раслый торган документ,

- баланың туу турындагы таныклыгының күчермәсе,

- үзара салым акчаларын түләү буенча бурычлар булмау турында белешмә.».

1.4. 6.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Вәкаләтле орган бирелгән документларны 30 календарь көн эчендә гомумиләштерә һәм эш кәгазе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына карар кабул итү өчен җибәрә.».

1.5. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Мөрәҗәгать итүчеләрнең кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү суммаларын күчерү Балтач муниципаль районының җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла.»

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе

А.Ф.Хәйретдинов